**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» апрель, 2020 ел № 549

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 19.12.2008 номерлы карарына (07.04.2020 ел № 490 үзгәрешләре белән) үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль ярдәмнең аерым чараларын күрсәтү срогын озайту турында» 2020 елның 01 апрелендәге 241 номерлы карарын үтәү йөзеннән Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2008 елның 19 декабрендәге №2008 (2020 елның 07 апрелендәге 490 номерлы үзгәрешләре белән) «Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы оешмаларга йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.5 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2020 елның 1 октябренә кадәр түләүләр чоры 2020 елның 30 сентябренә кадәр дәвам итә торган социаль ярдәм чараларын аларны алуга гариза кабат бирелмичә, дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларын карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация алучы гражданнарга, җан башына кереме 20 000 сумга кадәр булган гаиләләргә социаль ярдәм чараларын бирүне йөкләргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (http://www-pestreci.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 апреленнән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Район башкарма комитеты җитәкчесе А. В. Хәбибуллин